| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

01.07.2024 № 707

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Нурлат муниципаль районы Гражданнарны яклау идарәсе» МКУ хезмәткәрләренең гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендәге хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы 2020 елның 02 ноябрендәге 885 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендә муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәтенә түләүгә Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетлары чыгымнары күләмен билгеләү методикасына үзгәрешләр кертү турында" 2024 елның 10 маендагы 315 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләр булдыру турында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 14 августындагы 569 номерлы карары белән расланган “Нурлат муниципаль районының «Гражданнарны яклау идарәсе» МКУ хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү системасын камилләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Нурлат муниципаль районының «Гражданнарны яклау идарәсе» МКУ хезмәткәрләренең гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендәге хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакындагы» 2020 елның 02 ноябрендәге 885 номерлы карарының 2 пунктына, аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2020 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.».

2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 02 ноябрендәге 885 номерлы карары белән расланган “Нурлат муниципаль районы «Гражданнарны яклау идарәсе» МКУ хезмәткәрләренең гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендәге хезмәтенә түләү шартлары турындагы Нигезләмәнең

II бүлегендәге 4 пунктының 1 нче таблицасын яңа редакциядә бәян итеп үзгәреш кертергә:

Таблица 1

| № т/с | Хезмәткәрләрнең вазыйфалары | Вазыйфаи оклад күләме, сум |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Учреждение җитәкчесе | 25 014 |
| 2 | Оператив дежур учреждение | 19 242 |

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2024 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин